## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

**(V чакырылыш)**

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

## КАРАРЫ

«_07__» ___июль___2026 ел №_15 Урыссу ш.т.б.

Муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне 2027 елга, 2028 һәм 2029 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетына күчерүнең өстәмә нормативы белән алмаштыруны килештерү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 138 статьясындагы 5 пункты, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар чыгарды:

1. Муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне 2027 елга һәм 2028 һәм 2029 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетына күчерүләрнең өстәмә нормативы белән алмаштыруны килештерергә.
2. Әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте

һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы Район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин